# КАРАР

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге составына керүче Югары Тегермәнлек авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

22.10.2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә түбәндәге мәсьәлә буенча 2024 елның 22 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: « Сез 2025 елда балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек авылы торак пункты территориясендә теркәлгән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, мобилизацияләнгән гражданнарның гаиләләреннән тыш, 1 төркем инвалидларның һәм 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш һәм акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- урамнарны яктырту җайланмасы өчен;

-су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пункт территориясен төзекләндерү;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен 6 берәмлек контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

« КАРШЫ» «РИЗА»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 454 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 235 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«риза» позициясе өчен гражданнар җыенында 235 катнашучы тавыш бирде;

«каршы» позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес дип танырга.

2.«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, мобилизацияләнгән гражданнарның гаиләләреннән , 1 төркем инвалидлардан һәм 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2024 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә акча юнәлтергә ризамы:

- урамнарны яктырту җайланмасы өчен;

-су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пункт территориясен төзекләндерү;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен 6 берәмлек контейнер сатып алу, рөхсәтсез калдыкларны бетерү ;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Югары Тегермәнлек авылы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы, Совет урамы, 72А йорты, Балык

Бистәсе муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http:// ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълуматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru.урнаштырырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге башлыгы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Татарстан Республикасы М. Г. Мингарипов